**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 октябрь 2025ел № 361

**Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының 31.01.2025 №31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга автомобиль бензины сатуны чикләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 23 июлендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, прокурорның 29.09.2025 елгы протестына таянып, Әтнә район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 31.01.2025 ел, №31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә (Алга таба – исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. исемлекнең 2 нче графасына, 2.20. ТР КоАП статьясыннан соң түбәндәге эчтәлекле 2.22. статья ТР КоАП өстәргә:

«2.22. статья ТР КоАП Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.Ф. Каюмов